**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“15” ноябрь 2021 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге территориясендә 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Кызыл Утар авылы территориясен чистарту (үлән чабу, куаклар һәм агачлар кисү);

2) урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү;

3) Кызыл Утар авылында янгынга каршы җир асты су резервуары алу һәм урнаштыру (килешү буенча хезмәт хакы түләү);

4) туң җирне казу өчен бензин белән эшли торган җайланма сатып алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Кышлау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл-Утар авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Кашшапов А.Х.

Совет Кшкловского сельского поселения
Кышлау авыл җирлеге Советы